*Муниципль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ЭДЭБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)

**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Кайсы иҗат методы турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- ул татар әдәбиятында XIX гасырның икенче яртысында формалаша;
- аның тарафдарлары әдәбиятка тормышның актуаль проблемалары хакында уйлану мөмкинлеге итеп карыйлар;
- сурәтләү объекты итеп, тиз үзгәрүче дөньядагы эшлекле кеше сайлана; сюжет билгеле бер карашны расларлык яки кагарлык итеп корыла; кешене аң-белемгә өндәү, югары идеалларга хезмәт итәргә чакырыла; кеше табигатьтә яши дип, табигыйлык тәрбияләү шарты куела, кешегә тирәлекнең уңай һәм тискәре йогынтысы ассызыклана.

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) хикәя, повесть, роман, новелла

ә) дастан, бәет, мәдхия, мөнәҗәт

б) мәрсия, мәсәл, робагый, газәл

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)

  

а) ә) б)

 



**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл)**

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Искәндәр а) «Кыйссаи Йосыф»

2) Ягъкуб ә) «Тапшырылмаган хатлар»

3) Мәхмүт б) «Сүнгән йолдызлар»

4) Сәрвәр в) «Мәхәббәт тәүбәсе»

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, —
Парә-парә (телем-телем) кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, — әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак (бары тик) мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! —
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхрары мәхәббәт (мәхәббәт утында янган) миннән уңда, зан итәм (уйлыйм), —
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! — мин аларның таңчысы!

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)___________**

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)__________**

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә рус һәм чит әдәбиятларының кайсы күренекле вәкилләре искә алына? (3 балл)____________________________________________________________**

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**в) Лирик герой нинди хисләр кичерә? Ни сәбәпле? Шулар турында языгыз (3 балл)**_____________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз (3 балл)** _____________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл)**

*Аулак өй, кичен, җеп эрләү, бәйләү, чигү, сөлге, бирнә, кызлар, егетләр, гармун, күңелле, җыр-бию, уен-көлке, шат тавышлар.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

.